КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 май г.Казань № 358

3 яшьтән 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 296 номерлы карары белән расланган «Гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасына теркәлгән $7^1$ нче кушымтада китерелгән 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы чыгым

йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 2 май, 358 нче
карары белән расланды

3 яшьтән 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану
кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге (7 яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны (алга таба – субсидия) файдалану тәртибен билгели.

2. Федераль бюджеттан субсидия Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган шәхси счетка керә.

3. Субсидияне тоту бу Кагыйдәләрнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат алганнан соң биш эш көне эчендә финанслауның иң чик күләмнәрен Министрлыкка аның заявкалары буенча җиткерүгә чыгым расписаниесен Казначылыкка кертә.

5. Министрлык Казначылыктан субсидияләрне финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерүгә чыгым расписаниесен алганнан соң биш эш көне эчендә алга таба гражданнарның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына яки почта элемтәсе оешмалары аша күчерү өчен субсидияне финанслауның иң чик күләмнәрен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – Үзәк) җиткерүгә чыгым расписаниесен Казначылыкка кертә.

6. Үзәк ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 8еннән дә соңга калмыйча, финанслашу максатларында федераль бюджеттан субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турындагы хисапны Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Министрлыкка тапшыра.

7. Министрлык түбәндәгеләрне Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертә:

ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10ысыннан да соңга калмыйча, иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт

интеграцияләнгән мәгълүмат системасындагы электрон документ рәвешендә финанслашу максатларында федераль бюджеттан субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турындагы хисапны;

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасындагы электрон документ рәвешендә субсидиядән файдалану нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турындагы хисапны.

8. Бу Кагыйдәләрнең 7 нче пунктында күрсәтелгән хисаплар Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән формалар буенча тапшырыла.

9. Агымдагы финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә федераль бюджет керемен ә кире кайтарылырга тиеш.

Әгәр дә субсидиянең файдаланылмый калган өлеше федераль бюджет керемен ә күчерелмәгән булса, әлеге акча федераль бюджет керемен ә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

10. Министрлык һәм Үзәк тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидиянең максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

11. Бирелгән субсидияне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында гамәлгә ашырыла.

___________________________